КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 август г.Казань № 698

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2024 елларга Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү концепциясен раслау турында» 2021 ел, 29 гыйнвар, 35 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 май, 597 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2021 – 2024 елларга Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү концепциясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәламәтлек саклауны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының сәламәтлек саклауны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау,

янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сенябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 04 декабрь, 954 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында  Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

VIII бүлекнең 14 бүлекчәсенең бишенче абзацында «экологик күзәтчелек» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасын раслау турында» 2021 ел, 29 декабрь,  1314 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел,  24 декабрь,  1414 нче, 2023  ел, 28 апрель,  544 нче, 2023 ел, 03 ноябрь, 1419 нчы, 2024  ел, 26 февраль, 96 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының цифрлы трансформация программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа паспортында («Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

12.3.1 пунктның 3 графасында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

12.3.2 пунктның 3 графасында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

12.3.3 пунктның 3 графасында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

12.3.4 пунктның 3 графасында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

12.3.5 пунктның 3 графасында «экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

43 пунктның 4 графасында:

1 пунктның 1.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 11н номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2024 елның 16 апрелендәге 199н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның 2.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 16 августындагы 1342 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карары белән сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның 4.1 пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 16 августындагы 342 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карары белән сүзләренә алмаштырырга;

46 пунктның 4 графасындагы 1 пунктының 1.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 11н номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Аларның барлыкка килүе гражданнарга социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү чараларын, башка

социаль гарантияләрне һәм түләүләрне алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгалар белешмәлеген формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында» 2024 елның 16 апрелендәге 199н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

59 пунктның 4 графасының 6 пунктчасында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 - 2025 елларга республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм халыкның яшәү сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында» 2023 ел, 31 март, 385 нче карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 - 2026 елларга республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә биремнәрне раслау турында» 2024 ел, 15 март, 151 нче карары» сүзләренә алмаштырырга;

67 бүлекнең 4 графасының 1 пунктчасында «Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

68 бүлекнең 4 графасының 1 пунктчасында «Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

69 бүлекнең 4 графасының 1 пунктчасында «Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

71 бүлекнең 4 графасының 1 пунктчасында «Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

73 пунктның 4 графасында:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Мәгълүмат чыганаклары юк»;

5 пунктчаның икенче абзацын төшереп калдырырга;

75 пунктның 4 графасында:

1.1 пунктчада «Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктчаның икенче абзацын төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 21 февраль, 169 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 июль, 775 нче, 2023 ел, 29 декабрь, 1722 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә 13.11 пунктның 2 графасында

«экология күзәтчелеге» сүзләрен «экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Әлеге карар (әлеге карарның 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пункттагы унтугызынчы, 2 пункттагы дүртенче - сигезенче абзацларыннан, 3 пункттан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин